СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 14 » ноября 2023 ел** **№ 239**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау хакында» Арча район Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 98 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (28.02.2022 № 125, 25.04.2023 № 214 үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставына таянып, Арча район Советы карар бирде:

1.«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау хакында» Арча район Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 98 номерлы карарына (28.02.2022 № 125, 25.04.2023 № 214 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары дигән 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (htpp://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
_______________ ел, №__
карарына кушымта

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Контроль чара уздыру нәтиҗәсендә контрольдә тотылучы зат тарафыннан җир кишәрлеге мәйданының, аның турында мәгълүматлар Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында, җир кишәрлегенә хокук билгеләүче документларда булган җир кишәрлеге мәйданына туры килмәве.

2. контрольдә тотылучы зат тарафыннан җир кишәрлеген фактта куллану аның турында мәгълүматлар Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында, җир кишәрлегенә хокук билгеләүче документларда булган максатларда кулланууга туры килмәве.

3. Җир кишәрлеген озак вакыт үзләштермәү, җир кишәрлеге бирелгәннән соң өч елдан артык вакыт узган яки җир кишәрлеген аренда шартнамәсендә күрсәтелгән җир кишәрлеген үзләштерү вакыты тәмамланган, ә җир кишәрлегендә характерлы үзгәрешләр күзәтелми (капиталь төзелеш объекты, төзелеш эшләре алып бару һәм җир кишәрлеген рөхсәт ителгән файдалануга һәм бирү шартларына ярашлы рәвештә куллану буенча башка гамәлләр булмау).

4. Җир кишәрлекләреннән файдалану өчен нигез булып торган документларны рәсмиләштергәндә мәҗбүри таләпләрне үтәмәү.

5. Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында булган җир кишәрлеге чикләре урнашкан урынга карата җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталарын билгеләү төгәллеге (уртача квадрат хатасы) Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталарын төгәллеккә һәм билгеләү ысулларына таләпләрне, төгәллеккә таләпләрне һәм җир кишәрлегендә төзелеп бетмәгән бина, корылма, шулай ук бинаның мәйданын билгеләү таләпләрен раслау турында, корылмалар, биналар, машина урыннары яки объект контурының характерлы нокталары координаталарын билгеләү ысулларына таләпләр» 2020 елның 23 октябрендәге п/0393 номерлы боерыгы белән билгеләнгән күрсәткечтән артыграк зурлыкка тайпылуы.

6. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлегенең 20 һәм аннан да күбрәк процентын авыл хуҗалыгы белән бәйле булмаган башка әйберләр белән чүпләү («Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Максатчан билгеләнештәге җирләрдән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән файдаланмау яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдалану билгеләре турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1482 номерлы карары).

7. Күпьеллык җиләк-җимеш утыртмаларына карамаган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренең чүп үләннәре һәм (яки) агач-куак үсентеләре белән каплануы, авыл хуҗалыгы җитештерүен башкару яки авыл